- белем бирү оешмаларына яшь белгечләрне җәлеп итү буенча системалы эш алып барырга, шул исәптән педагогик юнәлеш буенча максатчан программалардан актив файдаланырга;
- мәгариф хезмәткәрләренең эш нәтиҗәләрен бәяләү күрсәткечләрен яхшыртырга;
- БДИдан 80 һәм югарырак балл җыйган укучылар санын арттырырга;
- ата-аналардан законсыз һәм мәҗбүри акча җыю очракларын булдырмаска;
- медиакиңлектә балаларның мәгълүмати куркынычсызлыгын тәэмин итү эшен дәвам итәргә.

**Тәрбия һәм өстәмә белембирү системасында:**

- яшьләр даирәсендә гомумроссия тәңгәллеген, милләтара һәм конфессияара татулыкны формалаштыруга юнәлдерелгән чаралар комплексын (юл картасын) эшләргә һәм расларга;
- ата-аналарның иҗтимагый берләшмәләрен үстерергә; ата-аналарны белем бирү оешмасы белән идарә итүгә, белем бирү сыйфатын бәяләүгә җәлеп итәргә;
- муниципаль психологик-педагогик үзәгенең эшчәнлеген үстерергә;
- 2020 нче елның 1 нче сентябреннән белем бирү оешмаларының башлангыч (1-4) сыйныф укучыларын кайнар ризык белән түләүсез тәэмин итү эшен оештырырга;
- 2020 нче елның 1 нче сентябреннән белем бирү оешмаларының мәгариф хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге өчен ай саен 5 000 сумнан ким булмаган күләмдә акчалата түләүләр оештырырга.

Муниципальное казенное учреждение
«Отдел образования исполнительного комитета
Высокогорского муниципального района
Республики Татарстан»

**РЕЗОЛЮЦИЯ**
**муниципального августовского совещания работников образования Высокогорского муниципального района «Приоритеты развития системы образования Высокогорского муниципального района в условиях реализации национального проекта «Образование»**

27.08.2020

*Проект*

С 17 августа по 21 августа 2020 года прошли заседания 18 секций муниципальной августовской педагогической конференции, в работе которых приняли участие 960 педагогов и руководителей общеобразовательных учреждений района. На секциях были рассмотрены вопросы, связанные с реализацией Национального проекта «Образование», актуальные вопросы повышения качества дошкольного и школьного образования, в том числе для детей с ограниченными возможностями здоровья; доступности и эффективности дополнительного образования детей. Педагоги отметили важность проблем и актуализировали задачи, которые предстоит решить в наступающем учебном году.

Заслушав и обсудив выступление главы Высокогорского муниципального района Калимуллина Р.Г., доклад заместителя руководителя исполнительного комитета - начальника отдела образования исполнительного комитета Высокогорского муниципального района Ахметзянова Н.К., участники пленарной части муниципального августовского совещания отмечают динамичное развитие муниципальной системы образования, обусловленное решением задач, поставленных стратегической целью Национального проекта «Образование» и направленных на достижение высокого качества образования посредством использования результативных подходов, эффективных инновационных методов и технологий в обучении и воспитании детей.

**Обсудив вопросы дальнейшего развития, в целях качественного, инновационного характера муниципальной системы образования участники совещания выработали следующие рекомендации на 2020/2021 учебный год.**

**В системе общего дошкольного образования:**

- обеспечить эффективность деятельности базовых ДОУ, в том числе в части методического сопровождения деятельности малокомплектных сельских детских садов;
- продолжить работу по повышению качества обучения детей двум государственным языкам Республики Татарстан;
- обеспечить непрерывное профессиональное развитие педагога ДОО, методическое сопровождение реализации ФГОС ДО;
- продолжить работу по созданию в детских садах условий, соответствующих ФГОС ДО, в том числе для детей с ограниченными возможностями здоровья;
- обеспечить соблюдение дошкольными образовательными организациями санитарных требований к образовательным организациям в условиях распространения новой коронавирусной инфекции;

**В системе общего школьного образования:**

- продолжить работу по реализации районной целевой программы «Программа развития образования Высокогорского муниципального района на 2019-2022 годы»;
- обеспечить реализацию комплекса мер федеральных проектов в рамках национального проекта «Образование»;
- повысить компетенцию педагогов в сфере изучения и применения компьютерных технологий, использования дистанционных образовательных технологий в образовательном процессе с учетом СанПИН;
- совершенствовать муниципальную модель системы оценки качества образования, в том числе с учетом технологий международных сопоставительных исследований PISA, TIMSS, PIRLS, всероссийских проверочных работ (ВПР);
- провести необходимые мероприятия по совершенствованию преподавания татарского языка и литературы в общеобразовательных учреждениях района;
- организовать работу по формированию и развитию полноценной татарской языковой среды в дошкольных, общеобразовательных учреждениях, а также поддержки изучения татарского языка, культуры и традиций в рамках дополнительного образования
- продолжить работу по развитию кадрового потенциала системы образования, используя механизмы оценки и стимулирования, повышению квалификации руководителей;
- обеспечить повышение управленческой компетенции руководителей ОУ.

- обеспечить реализацию Комплекса мер, направленных на создание условий для получения качественного общего образования в образовательных организациях со стабильно низкими результатами обучения;
- усилить работу по выявлению, поддержке и сопровождению одаренных школьников;
- вести работу по привлечению и закрепления молодых специалистов в каждом общеобразовательном учреждении, в том числе используя механизм целевого приема на педагогические направления подготовки;
- принять меры по совершенствованию показателей и критериев оценки результативности деятельности педагогических работников;
- вести работу по увеличению доли обучающихся с результатом 80 и более баллов;
- продолжить работу по недопущению незаконного и принудительного сбора денежных средств с родителей обучающихся и воспитанников;
- продолжить работу по обеспечению информационной безопасности детей в медиапространстве.

**В системе воспитания и дополнительного образования:**

- разработать и утвердить комплекс мер (дорожную карту), направленных на формирование общероссийской гражданской и татарстанской идентичности, межнационального и межконфессионального мира и согласия в молодежной среде;
- развивать родительские общественные объединения, привлекать родителей к участию в управлении образовательной организацией, к оценке качества образования;
- повысить качество услуг муниципальной психолого-педагогической службы;
- организовать работу по внедрению с 1 сентября 2020 года бесплатного горячего питания для обучающихся, осваивающих образовательные программы начального общего образования (1-4 классы) в общеобразовательных организациях района;
- осуществить с 1 сентября 2020 года выплаты ежемесячного денежного вознаграждения в размере не менее 5 000 руб. педагогическим работникам общеобразовательных организаций за классное руководство.

Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге»
муниципаль казна учреждениесе

**«Мәгариф» илкүләм проектын гамәлгә ашыру шартларында Биектау муниципаль районы мәгариф системасын үстерүнең өстенлекле юнәлешләре»**
**темасына**
**Биектау муниципаль районы мәгариф хезмәткәрләренең август киңәшмәсе**
**РЕЗОЛЮЦИЯСЕ**

27.08.2020

*Проект*

2020 нче елның 17 нче августына кадәр 960 педагогик хезмәткәр һәм җитәкче катнашында мәгариф хезмәткәрләренең муниципаль август киңәшмәсенең 18 секция утырышы үткәрелде. Секцияләр барышында «Мәгариф» илкүләм проектын гамәлгә ашыруга йомгак ясалды, мәктәпкәчә һәм мәктәп белеменең сыйфатын яхшырту (шул исәптән сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен дә өстәмә белем алу мөмкинлеге), тәрбия өлкәсенең нәтиҗәлелеге мәсьәләләре каралды. Педагоглар проблемаларның мөһимлеген ассызыклады, яңа уку елында хәл ителәсе бурыч һәм мәсьәләләрне билгеләде.

Биектау муниципаль районы башлыгы Р.Г.Кәлимуллинның чыгышын, Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – "ТР Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге" муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе Әхмәтҗанов Н.К. докладын тыңлап фикер алышканнан соң, киңәшмәдә катнашучылар "Мәгариф" илкүләм проектының стратегик максатына ирешү юлында куелган бурычларның хәл ителүен; нәтиҗәле алымнар, инновацион методлар һәм технологияләр куллану юлы белән муниципаль мәгариф системасының динамикалы һәм эзлекле үсешен билгеләп үтәләр.

**Муниципаль мәгариф системасының сыйфатлы, инновацион характердагы үсешен тәэмин итү максатын куеп, 2020/2021 нче уку елына түбәндәге тәкъдимнәр әзерләнде.**

**Гомуми мәктәпкәчә белем бирү системасында:**

- База балалар бакчаларының нәтиҗәле эшчәнлеген тәэмин итәргә, шул исәптән азкомплектлы балалар бакчаларына методик ярдәмне көчәйтергә;
- Татарстан Республикасы дәүләт телләренә өйрәтүнең сыйфатын арттыру буенча эшне дәвам итәргә;
- мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә эшләүче педагогларның үзлексез һөнәри үсешен булдырырга, федераль белем бирү стандартын гамәлгә ашыруны методик яктан тәэмин итәргә;
- яңа короновируслы инфекция таралу шартларында мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында санитария таләпләрен үтәү чараларын күрергә;
- балалар бакчаларында (шул исәптән сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен) федераль дәүләт белем бирү стандартына туры килә торган шартлар тудыру эшен дәвам итәргә тәкъдим итеlә.

**Гомуми белем бирү системасында:**

- "2019-2021 нче елларда Биектау муниципаль районы мәгарифен үстерү буенча максатчан район программасы"н гамәлгә ашыру буенча эшне дәвам итәргә;
- "Мәгариф" илкүләм проекты кысаларында федераль проектлар комплексын гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә;
- СанПИН таләпләрен исәпкә алып, укытучыларның дистанцион белем бирү һәм компьютер технологияләрен өйрәнү, белем бирү процессында куллану күнекмәләрен тулыландырырга;
- белем бирү сыйфатын бәяләү системасының муниципаль моделен, шул исәптән PISA, TIMSS, PIRLS халыкара чагыштырма тикшеренүләр технологияләрен исәпкә алып, бөтенроссия тикшерү эшләрендә (ВПР) катнашу белән камилләштерергә;
- белем бирү оешмаларында татар теле һәм әдәбиятын укытуны камилләштерергә;
- мәктәпкәчә, гомуми белем бирү оешмаларында сыйфатлы һәм тулы татар мохитен булдырырга; өстәмә белем бирү кысаларында татар телен, мәдәниятен һәм гореф-гадәтләрен өйрәнүгә ярдәм итәргә;
- бәяләү һәм ярдәм күрсәтү механизмнарын кулланып, мәгариф системасының кадрлар потенциалын үстерү, җитәкчеләрнең квалификацияләрен күтәрү буенча эшне дәвам итәргә;
- белем бирү оешмалары җитәкчеләренең идарәчелек компетенцияләрен арттыруны тәэмин итәргә;
- нәтиҗәләре түбән булган белем бирү оешмаларында сыйфатлы гомуми белем алу өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән чаралар комплексын гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә;
- сәләтле балаларны ачыклау, аларны үстерү һәм ярдәм итү эшен камилләштерергә;